ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ИСЛЯЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422970, Республика Татарстан,
Чистопольский район, с. Исляйкино,
ул. 8 марта, 19б

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСЛӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422970, Татарстан Республикасы,
Чистай районы, Исләй авылы,
8 март ур., 19б

e-mail: Isl.Ctp@tatar.ru тел. (84342) 3-09-26

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

22.06. 2023 ел № 23

Чистай муниципаль районының Исләй авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 20 декабрендәге «Чистай муниципаль районының Исләй авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында»гы 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законга нигезләнеп, Чистай муниципаль районы Исләй авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Чистай муниципаль районының Исләй авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 20 декабрендәге «Чистай муниципаль районының Исләй авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында»гы 6 номерлы карары белән расланган Чистай муниципаль районы Исләй авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3, 1.4, 1.7 пунктларында, 1.5 пунктындагы «б» пунктчасында, 2.4 пунктындагы «д» пунктчасының беренче һәм икенче абзацларында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында яисә Татарстан Республикасының рәсми хокукый

мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге Чистай муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга.

Исләй авыл җирлеге башлыгы В.П.Чернышев.